**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

2023 елның «20» ноябреннән　　　　　　　　　　№ 258

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында» 2022 елның 23 августындагы 227 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 08 декабрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 03 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2023 елның 20 июнендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыянны каплау кагыйдәләрен раслау турында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын үзгәртү һәм үз көчләрен югалткан дип тану хакында» 2020 елның 31 гыйнварындагы 67 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында» 2022 елның

23 августындагы 227 номерлы карарына, түбәндәге эчтәлектәге пункт өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«Әлеге карарның гамәлдә булу срогын 2024 елның 01 мартына кадәр билгеләргә».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (инфраструктур үсеш буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов